ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 04.12.2024 2008 **КАРАР**

«Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре
муниципаль берәмлеге территориясендә
бина фасадларын (алгы ягын) утлар
белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы
яңа ел бизәлеше» конкурсын үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга шәһәре муниципаль берәмлек территориясендә яңа ел бәйрәме мөхитен тудыру, халыкның эстетик мәдәниятен күтәрү һәм оешма, учреждение, кибет, уку йортлары, сәүдә павильоннары, кафе, ресторан хезмәткәрләренең һәм шәхси торак йортларында яшәүчеләрнең иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру максатларында, Алабуга шәһәре муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Предприятие, оешма, учреждение, уку йортлары, сәүдә, җәмәгать туклануы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүче оешмалар һәм шәхси торак йортлар арасында 2024 елның 9 декабреннән 2024 елның 22 декабренә кадәр түбәндәге номинацияләр буенча «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» шәһәр конкурсын үткәрергә:

1.1. Предприятие, оешма биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина янәшәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше;

1.2. Учреждение биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина тирәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше;

1.3. Сәүдә, җәмәгать туклануы һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүче оешма биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина янәшәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше.

1.4. Шәхси торак йортның иң яхшы яңа ел бизәлеше.

2. Оешма, сәүдә предприятиеләре, учреждение, сәүдә, җәмәгать туклануы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүче оешма җитәкчеләренә һәм шәхси торак йортында яшәүчеләргә бина фасадларын (алгы ягын) һәм янәшәсендәге территорияләрне бәйрәмчә бизәүне оештыруны һәм конкурста катнашуны тәкъдим итәргә.

3. «Яңа ел Алабугасы» конкурсын үткәрү турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

4. «Яңа ел Алабугасы» конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

5. Алабуга муниципаль районының «Алабуга яңалыклар хезмәте» автоном учреждениесенә (Г.Р. Сәлихова) конкурсны үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка хәбәр итүне тәкъдим итәргә.

6. Конкурста җиңүчеләргә акчалата бүләкләүне түбәндәге күләмдә расларга:

1 нче урын - 10 000 (ун мең) сум;

2 нче урын - 7 000 (җиде мең) сум;

3 нче урын - 5 000 (биш мең) сум итеп.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“____” ______ ____ел
карарына 1 нче
кушымта

**2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бина фасадларын (алгы ягын) утлар белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» конкурсын үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. 2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бина фасадларын (алгы ягын) утлар белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» конкурсы үткәрү турындагы Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) 2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бина фасадларын (алгы ягын) утлар белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» конкурсын үткәрүнең шартларын, тәртибен һәм процедурасын билгели (алга таба - Конкурс).

2. Конкурс ачык, бер этапта үткәрелә.

3. Конкурсның максаты - фасадларның, витриналарның, сәүдә залларының, предприятие һәм оешмаларга керү зоналарының эстетик матурлыгын арттыру, Яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәре алдыннан шәһәрдә бәйрәм образы тудыру, предприятиеләргә бина тирәсендәге территорияне төзекләндерү һәм бәйрәм мөхите (рухы) булдыру.

## 2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрүне Алабуга шәһәре Башкарма комитеты (алга таба - оештыручы) гамәлгә ашыра.

5. Конкурста Алабуга шәһәре территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, сәүдә, җәмәгать туклануы предприятиеләре, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүче оешмалар, шулай ук Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан шәхси торак йортта яшәүчеләр катнаша ала.

6. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Предприятие, оешма биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина тирәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше» (бина фасадларын, түбәсен (гөмбәзен), керү урыннарын, тәрәзәләрне яктылык элементлары, бәйрәм иллюминацияләре кулланып бизәү, кар корылмалары яисә боз скульптуралары, тау булдыру, агачларны, куакларны бизәү, территорияне санитар яктан карап тотуны күздә тота);

2) «Учреждение биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина тирәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше» (бина фасадларын, түбәсен (гөмбәзен), керү урыннарын, тәрәзәләрне яктылык элементлары, бәйрәм иллюминацияләре кулланып бизәү, кар корылмалары яисә боз скульптуралары, тау булдыру, агачларны, куакларны бизәү, уку йортларын, мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү территорияләрен санитаряктан карап тотуны күздә тота);

3) «Сәүдә, җәмәгать туклануы һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүче оешма биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина тирәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше» (бина фасадларын, түбәсен (гөмбәзен), керү урыннарын, тәрәзәләрне яктылык элементлары, бәйрәм иллюминацияләре кулланып бизәү, кар корылмалары яисә боз скульптуралары, тау булдыру, агачларны, куакларны бизәү, территорияне санитар яктан карап тотуны күздә тота);

4) «Шәхси торак йортның иң яхшы яңа ел бизәлеше».

7. Конкурс нәтиҗәләре буенча беренче өч номинациядә I, II, III урыннарны яулаучылар билгеләнә.

8. «Шәхси торак йортның иң яхшы яңа ел бизәлеше» номинациясендә конкурсның бер җиңүчесе билгеләнә.

9. Әгәр конкурска икедән ким гариза бирелсә, конкурс гамәлгә ашырылмаган дип танылa.

10. 2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бина фасадларын (алгы ягын) утлар белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» конкурсында катнашу өчен Конкурс комиссиясенә (алга таба - Конкурс комиссиясе) түбәндәге документлар тапшырыла: билгеләнгән рәвештә Конкурста катнашуга гариза (Нигезләмәгә кушымта);

11. Конкурста катнашуга гаризалар 2024 елның 12 декабреннән 2024 елның 22 декабрь көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр оештыручы тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә:

Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 12 нче йорт, 301 нче кабинет, белешмәләр өчен телефон: 3-31-81, 3-37-39.

## 3. Конкурс комиссиясе

12. Конкурс комиссиясе 9 кешедән тора. Аның составына конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары керә. Конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясенең 7 әгъзасы катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукка ия.

13. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа конкурс комиссиясе рәисе, секретаре һәм әгъзалары имза сала.

14. Комиссия рәисе:

1) Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

2) Конкурс комиссиясенең чираттагы утырышын уздыру датасын билгели, ә кирәк булган очракта чираттан тыш утырыш уздыру турында карар кабул итә;

3) Конкурс комиссиясе утырышларын үткәрә;

4) Конкурс комиссиясе карарларын һәм аларны кабул итүнең кыскача мотивировкасын игълан итә.

15. Комиссия рәисе булмаганда аның вазифасын комиссия рәисе урынбасары башкара.

16. Комиссия секретаре:

1) Конкурсны үткәрү турында хәбәрнамә текстын әзерли;

2) Конкурста катнашу өчен гаризалар терки, Нигезләмә нигезендә барлык документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген һәм барлык документларның булу-булмавын тикшерә;

3) Конкурс комиссиясе утырышын үткәрү урыны һәм вакыты турында конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына һәм әгъзаларына хәбәр итә;

4) Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен алып бара;

5) Конкурс комиссиясе утырышлары документларын саклауны тәэмин итә.

17. Конкурс комиссиясе үз компетенциясе чикләрендә конкурс үткәрү кагыйдәләрен һәм процедураларын башкарганда гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

18. Конкурс комиссиясе рәисенә, комиссия рәисе урынбасарына, комиссия секретаренә һәм әгъзаларына конкурс комиссиясе утырышларында фикер алышына торган мәсьәләләр, шул исәптән конкурста катнашуга гаризалар буенча фикер алышуга кагылышлы мәгълүматларны конкурс комиссиясе карарларыннан тыш белдерү тыела.

## 4. Конкурс җиңүчеләрен билгеләү

19. Конкурс комиссиясе конкурста җиңүчеләрне билгеләгәндә бәйрәмчә бизәлгән объектларны бәяләүнең түбәндәге критерийларына таянып эш итә:

1) сәнгатьчә һәм эстетик тамаша – 10 балл;

2) Яңа ел атрибутлары булу (Яңа ел чыршысы, гирляндалар, Яңа ел уенчыклары, әкият персонажлары (Кар кызы, Кыш бабай һәм башкалар) - максималь 10 балл;

3) карарларның оригинальлеге - иң югары балл - 8 балл;

4) техника һәм башкару сыйфаты - максималь иң югары балл - 8 балл;

5) яңа ел тематикасына рәсмиләштерү стиленә туры килү - максималь иң югары балл - 3 балл;

6) рәсмиләштерү стиленең бердәмлеге - максималь иң югары балл - 3 балл;

7) композициянең бөтенлеге - иң югары балл - 3 балл.

## 5. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү

20. Конкурсның беренче өч номинациясендә җиңүчеләр дип, объектларны карау һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча иң күп тавыш җыйган, конкурсның өч катнашучысы таныла.

21. Конкурс нәтиҗәләре 2024 елның 31 декабрендә шәһәрнең төп чыршысында тантаналы рәвештә игълан ителә, массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырыла.

2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре
муниципаль берәмлеге территориясендә
бина фасадларын (алгы ягын) утлар
белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы
яңа ел бизәлеше» конкурсын уздыру
турындагы Нигезләмәгә кушымта

**2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бина фасадларын (алгы ягын) утлар белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» конкурсында катнашуга гариза**

Датасы: "__"____________ 2024 ел.

КАТНАШУЧЫ:

| | |
|---|---|
| Оешманың исеме | |
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме<br><br>Оешма җитәкчесе | |
| Оешманың почта адресы | |
| Оешманың телефон, факс номеры | |
| e-mail,<br>оешма интернет-сайты адресы | |
| Конкурска тәкъдим ителә торган бәйрәмчә бизәлгән объект адресы | |
| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме,<br>контактлы затның вазыйфасы һәм телефоны | |

2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бина фасадларын (алгы ягын) утлар белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» конкурсына түбәндәге номинацияләрдә катнашуга ниятен белдерә:

| | |
|---|---|
| | «Предприятие, оешма биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина тирәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше» |
| | «Учреждение биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина тирәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше» |
| | «Сәүдә, җәмәгать туклануы һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүче оешма биналары фасадларын (алгы ягын) һәм бина тирәсендәге территорияләрнең иң яхшы яңа ел бизәлеше» |
| | «Шәхси торак йортның иң яхшы яңа ел бизәлеше» |

Конкурсны үткәрү тәртибе белән таныш һәм килешәм.

Белешмәләрнең тулысынча һәм дөреслеген гарантиялим (раслыйм).

_____________________________________________          ________________

Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме          (имза)

Мөһер урыны

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «___» ______
____ номерлы карарына
2 нче кушымта

**2024 елда «Яңа ел Алабугасы» - Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бина фасадларын (алгы ягын) утлар белән һәм сәнгатьчә бизәүгә «Иң яхшы яңа ел бизәлеше» конкурсын үткәрү буенча**
**КОНКУРС КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Томилин Андрей Александрович | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча җитәкче урынбасары, комиссия рәисе |
| Старогородцева Юлия Владимировна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Чумакова Кристина Олеговна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль планлаштыру бүлеге баш белгече, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Камалова Диләрә Әсһам кызы | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы |
| Курамшин Надир Дамир улы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Балобанова Алена Сергеевна | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Галимова Марина Борисовна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү секторы мөдире |
| Зиатдинов Илус Илгизәр улы | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль планлаштыру бүлеге башлыгы |
| Сайбель Екатерина Гарриевна | Алабуга муниципаль районы Советының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы (килешү буенча). |